ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 29.09.2021 г. Казань № 162-16/тэ-2021

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

«Татнефть-АЗС Центр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Чаллы филиалы тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү эшчәнлегенең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыруны туктатуга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Татнефть-АЗС Центр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Чаллы филиалыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 21.11.2018 № 5-26/тэ;

«Кулланучыларга «Татнефть-АЗС Центр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Чаллы филиалы тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2020 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 21.11.2018 № 5-26/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2020 ел өчен үзгәреш кертү турында» 27.11.2019 № 5-61/тэ.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.Л.Штром